| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

05.08.2014 Казан ш. № 1595-р

**“Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында, дәүләт учреждениеләренә оператив идарә хокукында билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.06.2012 ел, №2159-р Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

1. “Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында, дәүләт учреждениеләренә оператив идарә хокукында билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.06.2012 ел, №2159-р Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) боерыкның 3 пунктында “министр урынбасарына” дигән сүзләрне “министрның беренче урынбасарына” дигән сүзләргә алыштырырга;

2) боерык белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында, дәүләт учреждениеләренә оператив идарә хокукында билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Административ регламент):

а) 1.3.1 пунктта “,69” санын төшереп калдырырга;

б) 2 бүлектә:

Таблицаның беренче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт”; |

2.5 пунктта 1.3, 3.5, 4.3, 4.5, 5.3 пунктчаларны төшереп калдырырга;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 4 пунктчасын өстәргә:

“4. Күчемсез милек объектына, җир кишәрлегенә кадастр паспорты”;

в) 3 бүлектә:

3 бүлек атамасына “, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре” дигән сүзләр өстәргә;

3.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә һәм ярдәм күрсәтә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, аларны рәсмиләштерү буенча һәм дәүләт хезмәте алуга кагылышлы башка мәсьәләләр буенча.”;

3.3.4 пунктта дүртенче абзацтан соң түбәндәге эчтәлектәге бишенче абзацны өстәргә:

“җир кишәрлегенең һәм күчемсез милек объектының кадастр паспортларын “Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең федераль кадастр палатасы” федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына (алга таба – ФКП) тапшыру турында”;

Түбәндәге эчтәлектәге яңа 3.3.4[1] пунктны өстәргә:

“3.3.4[1]. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша сорала торган документларны (мәгълүматлар) билгеләнгән срокта тапшыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торучы

документларны, мәгълүматларны яки баш тарту турында белдерү кәгазен Министрлыкка җибәрү.";

Түбәндәге эчтәлектәге 3.3.9 пунктны өстәргә:

"3.3.9. "Дәүләт хезмәте электрон рәвештә һәм күп функцияле үзәк аша күрсәтелми.";

г) 4 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 4.4 пунктны өстәргә:

"4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдәге эшчәнлегенең хәбәрдарлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу юлы белән хәл ителә.";

д) 5 бүлектә:

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.3. Шикаять почта аша, күп функцияле үзәк аша, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.";

5.4 пунктның 1 пунктчасында "запрос" дигән сүзне "мөрәҗәгать" дигән сүзгә алыштырырга;

бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5.10 пунктны өстәргә:

"5.10. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.";

е) Кушымтада Административ регламентка №1 кушымтаның 2 пунктын төшереп калдырырга;

ж) Кушымтада Административ регламентка №3 кушымтаның 4 пунктын төшереп калдырырга;

з) Кушымтада Административ регламентка №4 кушымтаның 2 һәм 4 пунктларын төшереп калдырырга;

и) Кушымтада Административ регламентка №5 кушымтаның 2 пунктын төшереп калдырырга;

к) Административ регламентка №№6 һәм 7 (белешмә) кушымталарны яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итәргә.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

**Министр** **А .К.Хамаев**

Татарстан Республикасы милкендәге
мөлкәтне дәүләт унитар
предприятиеләренә хуҗалык алып
бару хокукында, дәүләт
учреждениеләренә оператив идарә
хокукында билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
№6 кушымта

**Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында, дәүләт учреждениеләренә оператив идарә хокукында билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелегенең блок-схемасы**

Мөрәҗәгать итүче

Мөрәҗәгать итүче (вәкиле) бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза белән документлар тапшыра

Гариза, документлар

Бүлек белгече

Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен тикшерә. Документларның бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән исемлеккә туры китереп тапшырылу-тапшырылмавын һәм бу Регламентның 2.8 пунктында күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең булу-булмавын тикшерә. Мөрәҗәгать итүчеләрне учетка алу кенәгәсенә документларны кабул итү

Документларны кабул итүдән баш тарту яки мөрәҗәгать итүчегә исемлек

Мөрәҗәгать итүче

Гариза һәм документларны тикшерү, гаризага кушып бирелгән документларның

Канцелярия эшләрен башкару бүлеге белгече

1көндә документларны кабул итә, гариза һәм документларны терки

Документларны кабул итү, теркәү

Бүлек белгече


Бу Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләрнең булу-булмавын тикшерә. УФНС ТР, Росреестр ТР, ТР Мәдәният министрлыгы, ФКП га запрослар җибәрә 4 көн

УФНС ТР, Росреестр ТР , ТРМәдәният министрлыгына,

Министрлык запросларына УФНС ТР, Росреестр ТР, ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан документлар әзерләү

Министрыкның карары проектын яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, әзерли 7 көн

Министрлыкның карары проекты яки баш тарту турында хат проекты


Бүлек начальнигы
Министрлыкның карары проектын яки баш тарту турында хат проектын карап тикшерә һәм килештерә
1 көн
Министрлыкның карары проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерү
Бүлек белгече
Министрлың карары проектын яки баш тарту турында хат проектын министр урынбасарына имза салдыруга җибәрә
Проектларны министр урынбасарына имза салдыруга җибәрү
Министр урынбасары
Министрлыкның карары проектын имзалый яки, баш тарту турында хатны имзалап, делопроизводство бүлегенә теркәүгә җибәрә
1 көн
Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатны имзалау
Министрлыкның карары проекты
Канцелярия эшләрен башкару бүлеге белгече
Министрлыкның карарын терки яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатны теркәп, мөрәҗәгать итүчегә җибәрә
1 көн
Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү
Министрлык карарын теркәү
Канцелярия эшләрен башкару бүлеге белгече
Мөрәҗәгать итүчегә Министрлык карарын бирә
Мөрәҗәгать итүчегә Министрлык карарын бирү

Татарстан Республикасы милкендәге
мөлкәтне дәүләт унитар
предприятиеләренә хуҗалык алып бару
хокукында, дәүләт учреждениеләренә оператив
идарә хокукында билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
№7 кушымта (белешмә)

**Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәтне дәүләт унитар предприятиеләренә хуҗалык алып бару хокукында, дәүләт учреждениеләренә оператив идарә хокукында билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аны күрсәтүгә контрольлек итүче вазыйфаи затларның реквизитлары**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221 -40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Демидов Сергей Анатольевич | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Мөлкәт идарәсе начальнигы<br>Сафина Фәнисә Рәшит кызы | 221 -40-25 | Fanisa.Safina@tatar.ru |
| Дәүләт мөлкәтеннән файдалану бүлеге начальнигы<br>Альмукова Инна Наил кызы | 221-40-28 | Inna.Almukova@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен башкару һәм контрольлек бүлеге начальнигы<br>Румянцева Гөлнур Ниязи кызы | 221-40-81 | Gulnur.Rumyanceva@.tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты
икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе начальнигы Нафигин Альберт Ильдар улы | 264-77-22 | Albert.Nafigin@tatar.ru |
| Идарә начальнигы урынбасары Зарипов Ирек Фирдинант улы | 264-77-37 | Irek.Zaripov@tatar.ru |